**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Наратлы Кичү авыл җирлеге Советы карары**

**18.12.2020 ел** **№ 2**

**«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»**

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында “2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы”, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" законы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 5.2.1 п. 5.2 п. пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2.1. Җирлек территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү региональ программа, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге региональ программа һәм калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасы (алга таба - калдыклар белән эш итү схемасы) нигезендә, кулланучылар белән төзелгән каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр нигезендә, төбәк операторлары тарафыннан тәэмин ителә.

Региональ оператор каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшләрен мөстәкыйль рәвештә яки каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларны җәлеп итеп башкара.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләренең I бүлегендә каралган тәртиптә, каты коммуналь калдыклар барлыкка килә һәм аларның туплану урыннары (мәйданчыклары) урнашкан эшчәнлек зонасында кулланучы һәм региональ оператор арасында төзелә.

1.2. 5.2.3 п. 5.2 п. пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2.3 Калдыкларны саклау - махсуслашкан объектларда калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, күмү максатларында унбер айдан артык вакытка туплау.»

1.3. 5.2.18 п. 7 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.4. 5.5.2.п. 14 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.6. 3.6.8 п. 3 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.7. 6.2.4 п. 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.4. Милекче үз теләге белән үзенә караган мөлкәткә карата законга һәм башка хокукый актларга каршы килми торган һәм башка затларның закон белән саклана торган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозмый торган теләсә нинди гамәлләр кылырга, шул исәптән үз мөлкәтен башка затлар милкенә читләштерергә хокуклы. Милекче булып калып, милеккә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү хокукларын тапшырырга, милекне залогка бирергә һәм башка ысулларны йөкләргә, җир һәм башка табигый ресурслардан файдалану һәм идарә итү, аларның әйләнеше закон белән рөхсәт ителгән очракта, милекче тарафыннан ирекле гамәлгә ашырыла, әгәр бу әйләнә-тирә мохиткә зыян китерми һәм башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмый икән».

2. Әлеге Карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясында каралган тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Минзәлә муниципаль районы
Наратлы Кичү авыл җирлеге башлыгы Вәлиев И.М.